ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе**
Кама Тамагы районы,
Келәнче авылы
тел. 8-(84377)- 33-4-31

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Руководитель Исполнительного комитета Клянчеевского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Клянчеево
тел. 8-(84377)- 33-4-31

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 елның 10 ноябре** **№ 17**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясендә йорт хайваннарының йөрү урыннарын билгеләү турында "

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 елның 11 августы № 971 «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклауны тәэмин итә торган йорт хайваннарын йөртү өчен шартлар тудыру максатларында, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге» **карар бирә**:

1. Йорт хайваннарын йөртү өчен рөхсәт ителгән урын (урыннар) итеп билгеләргә:

- Келәнче авылының көньяк ягындагы Шахъян елгасы буендагы көтүлектә һәм Бәки авылы көтүлегендә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче ав., Г.Тукай ур., 35 й.;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур., һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Д.А.Кадыров